**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“28” ноябрь 2021 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Олы Мәңгәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Олы Мәңгәр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Олы Мәңгәр авылының Пролетарская һәм Татарстан урамнарында асфальт-бетон өслеген ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Олы Мәңгәр авылында балалар өчен уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Олы Мәңгәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Мәңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Тахавиев Ф.К.